КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 октябрь г.Казань № 973

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципаль-ара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характер-дагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характер-дагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 8 август, 645 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Төбәк дәүләт күзәтчелеге шулай ук куркынычка йөз тоткан якын килүне кулланып гамәлгә ашырыла.»;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 12 – 22 пунктлар өстәргә:

«12. Төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда куркынычка йөз тоткан якын килүне куллану максатларында юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркынычка йөз тоткан якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 17 август, 806 нчы карары белән расланган Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар файдалана торган җитештерү объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә яки куркынычның билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре нигезендә куркынычның билгеле бер категориясенә кертелергә тиеш.

Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркынычның билгеле бер категориясенә кертү әлеге Тәртипкә кушымтада китерелгән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркынычның билгеле бер категориясенә кертү критерийләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата планлы тикшерүләр үткәрү юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлегенә бирелгән куркыныч категориясенә бәйле түбәндәге вакыттан вакытка кабатлана:

югары куркыныч категориясе өчен – ике елга бер тапкыр;

сизелерлек куркыныч категориясе өчен – өч елга бер тапкыр.

Эшчәнлекләре түбән куркыныч категориясенә кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә мөнәсәбәттә планлы тикшерүләр үткәрелми.

14. Планлы тикшерүне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертү өчен нигез булып тикшерү үткәрелә торган елда түбәндәге датадан билгеләнгән вакыт чоры узып китү тора:

а) куркынычның III һәм (яки) IV классларындагы куркыныч җитештерү объектларын яисә III һәм (яки) IV классларындагы гидротехник корылмаларны юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдалана башлау;

б) балалар ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру өлкәсендә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау;

в) юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәгариф өлкәсендә һәм тиз үсеш ала торган куркыныч табигать күренешләре һәм техноген процесслар барлыкка килү куркынычына дучар ителгән территориядә урнашкан эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау;

г) юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан яшәүне тәэмин итү белән социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау, шулай ук стационар медицина ярдәме күрсәтү;

д) юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тиз үсеш ала торган куркыныч табигать күренешләре һәм техноген процесслар барлыкка килү куркынычына дучар ителгән территориядә эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау;

е) юридик затларны (аларның структур бүлекчәләрен) һәм шәхси эшмәкәрләрне яки алар карамагындагы оешмаларны һәм әлеге оешмаларның структур бүлекчәләрен билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм

бетерү бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системалары көчләре составына кушу (кертү);

ж) әлеге пунктның «а» – «д» пунктчаларында күрсәтелгән оешмалар, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр пунктчаларында күрсәтелгән согы планлы тикшерү үткәрү тәмалану.

15. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркыныч категорияләренә кертү вәкаләтле орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

16. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркыныч категорияләренең берсенә кертү турында карар яңадан каралган очракта куркыныч категориясен үзгәртү турында карар вәкаләтле орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан кабул ителә.

Билгеле бер куркыныч категориясенә кертү турында карар булмаганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге түбән куркыныч категориясенә кертелгән дип санала.

17. Вәкаләтле орган планлы тикшерүләр алып барыла торган юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлеген алып бара.

Эшчәнлекләре куркыныч категориясенә кертелгән юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләр алып барыла торган юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлекләренә кертү җитәкченең (җитәкче урынбасарының) юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркынычның тиешле категорияләренә кертү турында карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

18. Планлы тикшерүләр алып барыла торган юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлекләре түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) эшчәнлекләре югары һәм сизелерлек куркыныч категориясенә кертелгән юридик затның тулы исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе һәм әтисе исеме (булганда);

б) юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең төп дәүләт теркәү саны;

в) салым түләүченең индивидуаль номеры;

г) эшчәнлекләре югары һәм сизелерлек куркыныч категориясенә кертелгән юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны;

д) куркыныч категориясе бирү турында карар реквизитлары, куркыныч категориясенә күрсәтмә, шулай ук алар нигезендә юридик зат һәм шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән мәгълүматлар.

19. Вәкаләтле органның рәсми сайтында эшчәнлекләре планлы тикшерүләр үткәрелгән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлекләрендәге югары һәм сизелерлек куркыныч категорияләренә кертелгән юридик затлар турында һәм шәхси эшмәкәрләр хакында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла һәм актуальләштерелә:

а) эшчәнлекләре югары һәм сизелерлек куркыныч категорияләренә кертелгән юридик затның тулы исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм әтисе исеме (булганда);

б) салым түләүченең индивидуаль саны;

в) эшчәнлекләре югары һәм сизелерлек куркыныч категорияләренә кертелгән юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны;

г) куркыныч категориясе һәм юридик зат яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул итү датасы.

20. Әлеге Тәртипнең 19 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны урнаштыру дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

21. Эшчәнлекләре куркыныч категорияләренең берсенә кертелгән юридик зат яки шәхси эшмәкәр соравы буенча вәкаләтле орган билгеләнгән тәртиптә юридик затка яки шәхси эшмәкәргә алар эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турында мәгълүматны, шулай ук юридик зат яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркыныч категорияләренең берсенә керткәндә файдаланылган белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә юридик затка яки шәхси эшмәкәргә бирә.

22. Эшчәнлекләре куркыныч категорияләренең берсенә кертелгән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле органга аларга элек бирелгән куркыныч категориясен үзгәртү турында гариза бирергә хокуклы.»;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта

Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне
билгеле бер куркыныч категориясенә кертү критерийләре

1. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеген бәяләүне һәм юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлегенең потенциаль тискәре нәтиҗәләре авырлыгын исәпкә алып, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге куркынычның түбәндәге категорияләренә кертелергә тиеш:

а) югары куркыныч категориясенә:

куркынычның III һәм (яки) IV классларындагы куркыныч җитештерү объектларын яисә III һәм (яки) IV классларындагы гидротехник корылмаларны файдаланучы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге;

балалар ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру өлкәсендә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге;

мәгариф өлкәсендә һәм тиз үсеш ала торган куркыныч табигать күренешләре һәм техноген процесслар барлыкка килү куркынычына дучар ителгән территориядә урнашкан эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге;

яшәүне тәэмин итү белән социаль хезмәтләр күрсәтү, шулай ук тиз үсеш ала торган куркыныч табигать күренешләре һәм техноген процесслар барлыкка килү

куркынычына дучар ителгән территориядә стационар медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге;

б) сизелерлек куркыныч категориясенә – юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге, әгәр әлеге юридик затлар (аларның структур бүлекчәләре) һәм шәхси эшмәкәрләр яки алар карамагындагы оешмалар һәм әлеге оешмаларның структур бүлекчәләре билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системалары көчләре составына кушылган (кертелгән) булса;

в) түбән куркыныч категориясенә – әлеге пунктның «а» – «б» пунктчаларында күрсәтелгән бүтән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге, әгәр әлеге юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген югары яки сизелерлек куркыныч категориясенә кертү критерийләренә туры килүдән туктаса.

2. Югары һәм сизелерлек куркыныч категориясенә кертелергә тиеш юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге законлы көченә кергән һәм соңгы планлы тикшерүдә ачыкланган Россия Федерациянең Административ хокук бозулар турында кодексының 20.5 һәм 20.6 статьяларында каралган административ хокук бозулар кылган өчен юридик затка һәм (яки) аның вазыйфаи затларына, шәхси эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында суд карары булмаганда, тиешенчә сизелерлек һәм түбән куркыныч категориясенә кертелергә тиеш.

3. Сизелерлек һәм түбән куркыныч категориясенә кертелергә тиеш юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге законлы көченә кергән һәм соңгы планлы тикшерүдә ачыкланган Россия Федерациянең Административ хокук бозулар турында кодексының 9.19 статьясы, 19.4 статьясының 1 өлеше, 19.5 статьясының 1 өлеше, 19.5.1, 19.6, 19.7, 20.5 һәм 20.6 статьяларында каралган административ хокук бозулар кылган өчен юридик затка һәм (яки) аның вазыйфаи затларына, шәхси эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында суд карары булганда тиешенчә югары һәм сизелерлек куркыныч категориясенә кертелергә тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин